

Инсар районына, эш сәфәре кысаларында, Мордовия Дәүләт Җыелышы рәисе балаларнын жәйге ялы объектларында булды. Алар арасында В.Я. Антропов исемендәге Инсар балалар сәламәтләндерv лагеры. Быел бирeдә 80 балага ике смена узачак, беренчесе 24 июньдә башланачак. Хәзер әзерлек эшләре актив бара. Владимир Чибиркин район башлыгы Харис Якуббаев һәм лагерь житәкчелеге белән йокы корпусларында капиталь ремонт барышы белән танышты: канализация тозелеше алып барыла, душ кабиналары һәм санузеллар урнаштырыла, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры китереп эвакуация чыгу юллары жиһазландырылачак. «Киләчәктә лагерь ел әйләнәсе булырга момкин. Монын очен техник момкинлекләр бар: газ, электр энергиясе, сууткәргеч. Якында гына матур чиста елга. Район планнарында бу бар, һәм республика проектны хуплаячак», - дип билгеләп vтте Владимир Чибиркин.
Икенче Инсар урта мәктәбендә Мордовия Дәvләт Жыелышы Рәисенә «Эрудит», «Радуга» һәм «Ударник» лагерьлары эше турында сойләделәр. Смена балаларнын ял итvенә генә тvгел, ә аларнын белем дәрәжәсен кvтәрvгә дә исәпләнгән. Мәсәлән, «Эрудит» торкемендә катнашучылар арасында фән олимпиадалары призерлары да бар, «Үсеш ноктасында» дәресләр оештырылган. Владимир Чибиркин балалар белән аралашты: фәннен әһәмияте турында сойләделәр, укучыларнын һонәри киләчәге мәсьәләләренә кагылды.
Мордовия Дәvләт жыелышы спикеры Русская Паевка авылында «Улыбка» исемле тагын бер мәктәп яны лагеренда булды. Уку йорты житәкчелеге һәм аларнын тәрбияләнvчеләре белән очрашу вакытында анда ял чарасы vткәрелә. Балалар Пушкиннын шигырьләрен укыйлар һәм лагерьда аларга нәрсә ошаганын рәхәтләнеп сойлиләр.
«Жәйге ялны оештыру мәсьәлә-ләренә Мордовия Главасы Артём Алексеевич Здунов зур игътибар бирә. Закон чыгару һәм башкарма хакимият органнарына йокләмәләр бирә. Бездә заманча һәм унайлы балалар лагерьлары, тозекләндерелгән пляжлар булырга тиеш, анда республика халкы һәм кунаклары коч жыя алыр иде. Монын очен барлык шартларны, шул исәптән объектларда куркынычсыз булуны да булдырырга кирәк. Депутатлар корпусы бу эшкә актив катнаша, сәламәтләндерv кампаниясен әзерләvне һәм vткәрvне контрольдә тота», – диде Владимир Чибиркин Инсар районында жәйге ял инфраструктурасы белән танышу нәтижәләре буенча.

**Наилә НАСЫРОВА**